Зарегистрирован в Управлении Министерства юстиции Российской Федерации в Республике Татарстан
Свидетельство о государственной регистрации Устава муниципального образования город Нижнекамск Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан
№ RU 165301172022001 от 18 января 2022 года


РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru


РЕШЕНИЕ КАРАР

2021 елның 17 декабре № 70

## Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьялары, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 94, 95, 96 статьялары нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен карап, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 14 апрелендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.
3. Түбән Кама шәһәре Мэрына әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры вазыйфаларын башкаручы, Мэр урынбасары М.В. Камелина

Түбән Кама шәһәр Советының
2021 елның 17 декабрендәге
70 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. «Шәһәрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 6 статьясындагы 1 өлешендә:

4.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1) җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләрнең үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»

- 5 пунктчада «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләренә алмаштырырга;

- 21 пунктчада «аларның үтәлешен тикшереп тору» сүзләрен «аның предметы булып, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларын һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү таләпләрен үтәү торган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

- 28 пунктчада «файдалану һәм саклау» сүзләрен «саклау һәм файдалану» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Шәһәр Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 42 статьясындагы 1 өлешенең 7 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе катнашучысы - чит ил гражданлыгын туктату, чит ил гражданлыгы (подданство) яисә яшәүгә рөхсәт кәгазе, яки Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданының, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә башкасы каралмаган булса, чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булу;».

3. «Шәһәр Мэры вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 48 статьясындагы 1 өлешенең 8 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«8) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе катнашучысы - чит ил гражданлыгын туктату, чит ил гражданлыгы (подданство) яисә яшәүгә рөхсәт кәгазе, яки Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданының, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә башкасы каралмаган булса, чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булу;».

4. «Шәһәр башкарма комитеты вәкаләтләре»51 статьясында:

- 3 пунктның 3.8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. шәһәр территориясендә дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны саклауны оештыру, үстерү һәм тәэмин итүне гамәлгә ашыра, шулай ук җирле әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

- 4 пунктның 4.6 пунктчасында «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләренә алмаштырырга;

- 5 пунктның 5.16 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.16) җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләрнең үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;»;

- 6 пунктның 6.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. аның предметы булып, шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларын һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү таләпләрен үтәү торган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә шәһәр территориясен төзекләндерүне оештыра, шулай ук шәһәр урманнарын, шәһәрнең торак пунктлары чикләрендә урнашкан аеруча саклана торган табигать территорияләрен файдалануны, саклауны, яклауны, яңадан җитештерүне оештыра;».

5. 52 статьяда «шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе» 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4) шәһәр Мэрына язма формада Россия Федерациясе гражданлыгын яисә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе катнашучысы - чит ил гражданлыгын туктату, яки чит ил гражданлыгы (подданство) алу яисә яшәүгә рөхсәт кәгазе, яки Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданының чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алу турында бу хакта аңа билгеле булган көнне, ләкин Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданлыгы туктатылган яки чит ил гражданлыгы (подданство) алган, яисә яшәүгә рөхсәт кәгазе яки әлеге пунктта каралган башка документ алган көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә бурычлы.»

6. «Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү тәртибе» 53 статьясының 3 пунктында:

- б) пунктчасында «3 пунктның «в», «г» пунктчаларында каралган» сүзләрен «3 пунктның «в» пунктчасында каралган» сүзләренә алмаштырырга;

- в) пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«в) муниципаль хезмәт яки аларга тиңләштерелгән дәүләт хезмәте вазыйфалары стажы кимендә ике ел, яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажы кимендә дүрт ел.»;

- г) һәм д) пунктчаларын төшереп калдырырга.

7. «Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 56 статьясындагы 1 өлешенең 9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«9) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе катнашучысы - чит ил гражданлыгын туктату, чит ил гражданлыгы (подданство) яисә яшәүгә рөхсәт кәгазе, яки Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданының, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә башкасы каралмаган булса, чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булу;».

8. «Шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләре эчтәлеге» 73.1 статьясының 2 өлешендәге 17 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары М.В. Камелина